**СОВЕТ КУТЕМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
ЧЕРЕМШАНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Клубная, д.1а, село Кутема, 423112

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**КҮТӘМӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
Клуб урамы, 1а йорты, Күтәмә авылы, 423112

тел.+7(84396) 4-30-88, e-mail: Kut.Cmn2@tatar.ru

№111 20 июнь 2024 ел

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы
Күтәмә авыл җирлеге Советы
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Күтәмә авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Күтәмә авыл җирлеге депутатларының, даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайлап куелган җирле үзидарә вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 25 апрелендәге 83 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Муниципаль берәмлекләр башлыкларына, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларына, депутатларга, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы сайлап куелган җирле үзидарә органнары әгъзаларына, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренә һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларына айлык акчалата бүләкләү күләмен арттыру турында» 2024 елның 28 мартындагы 182 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Күтәмә авыл җирлеге Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Күтәмә авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Күтәмә авыл җирлеге депутатларының, даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайлап куелган җирле үзидарә вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 25 апрелендәге 83 номерлы карарына (җирлек Советының 2020 елның 20 октябрендәге № 8; 2022 елның 01

ноябрендәге № 67, 2023 елның 31 гыйнварындагы №76 карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 өлешнең 3 абзацын бәян итәргә: «Авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең хезмәт хакы күләме 13323 сум тәшкил итә»;

1.2. 7 нче кушымтада III бүлекнең 1 пунктнының 6 пунктчасын бәян итәргә: «6) айлык акчалата бүләкләү - вазыйфаи хезмәт хакының 41 процентыннан артмаган күләмдә.»

1.3. 7 нче кушымтада 1 нче пунктны бәян итәргә: «1. Муниципаль хезмәткәрләргә премиядән тыш ай саен акчалата бүләкләүләр дә түләнә. Муниципаль хезмәткәрләргә айлык акчалата бүләкләү җирле үзидарә органы җитәкчесе карары белән вазыйфаи хезмәт хакының 41 процентыннан артмаган күләмдә билгеләнә».

1.4. «2 нче кушымтаны «Авыл җирлегендә үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы авыл җирлеге башлыгының айлык акчалата бүләкләү күләмнәре» 1 нче кушымтага ярашлы рәвештә яңа редакциядә бәян итәргә.

1.5. 1 нче кушымтада I бүлекнең 3 нче пунктында бәян итәргә: «Авыл җирлеге башлыгына ай саен акчалата бүләк бирелә. Күрсәтелгән затларның хезмәт хакына айлык акчалата бүләкләү өлешендә чыгымнар күләме башлыклар өчен елына айлык акчалата бүләкләүнең 12,86 тәшкил иткән нормативыннан артмаска тиеш»

2. Әлеге карарны рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2024 елның 1 июленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Күтәмә авыл җирлеге
Советы рәисе, башлыгы Н.Г. Сабиров

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Күтәмә авыл җирлеге
Советының 2024 елның 20 июнендәге
№ 111 карарына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Күтәмә авыл җирлеге
Советының 2018 елның 25 апрелендәге
№ 83 карарына 2 нче кушымта

Авыл җирлегендә үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы авыл җирлеге башлыгының айлык акчалата бүләкләү күләме

| Вазыйфа атамасы | Акчалата бүләкләү күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Башлык | 18260,00 |